КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 24 гыйнвар г.Казань № 37

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге («С» категорияле йөртүче) буенча гражданнарны әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 18 июнь, 481 нче карары белән расланган 837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге («С» категорияле йөртүче) буенча гражданнарны әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге («С» категорияле йөртүче) буенча гражданнарны әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 18 июнь, 481 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 16 август, 839 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге («С» категорияле йөртүче) буенча гражданнарны әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталындагы «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

8 пунктның өченче абзацында «30 календарь көннән иртәрәк» сүзләрен «бишенче календарь көннән иртәрәк» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктның беренче абзацында «алучылар» сүзен «алучы» сүзенә алмаштырырга;

21 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21. Субсидия алучы субсидия керү һәм аны тоту буенча аерым бухгалтерлык исәбен алып бара.»;

24 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткечләре (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин